ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 30 » декабрь 2016 ел** **№ 1385**

**«Арча муниципаль районының муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм муниципаль учреждениеләр башкара торган эшләрнең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау турында» Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 26 августындагы 839 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 26 февралендәге 151 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең база (тармак) исемлекләрен булдыру һәм алып бару, дәүләт хезмәтләренең һәм федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган эшләрнең ведомство исемлекләрен формалаштыру, алып бару һәм раслау турында һәм дәүләт (муниципаль) хезмәтләре һәм дәүләт учреждениеләре (муниципаль учреждениеләр) тарафыннан башкарыла торган эшләрнең ведомство исемлекләрен формалаштыруга, алып баруга һәм раслауга гомуми таләпләр хакында» карарын гамәлгә ашыру максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 26 августындагы 839 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль учреждениеләрнең башкарыла торган һәм башкарыла торган эшләрнең ведомство исемлекләрен төзү, алып бару һәм раслау турында» карарына үзгәрешләр кертергә:

2. Карарның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Арча муниципаль районы башкарма комитетының гамәлгә куючы вәкаләтләренең бер өлеше тапшырылган җирле үзидарә органнарына (МУ «Мәгариф идарәсе» МУ Арча муниципаль районы «Мәдәният идарәсе» МУ, Арча муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы) әлеге карарның 1 пункты белән расланган Тәртип нигезендә муниципаль хезмәт

күрсәтүләрнең һәм муниципаль район учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган эшләрнең ведомство исемлеген төзергә һәм аларны гамәлгә куючыга раслауга тапшырырга.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Ф.Р. Исмәгыйлевка йөкләргә.

Җитәкче И.Ә.Галимуллин